РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2022 елның 29 декабре** **Чистай шәһәре** **№19/2**

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советының 2019 елның 19 сентябрендәге 38/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 5 декабрендәге 512-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советының 2019 елның 19 сентябрендәге 38/1 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советының 2020 елның 28 октябрендәге 3/3 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль милекне хосусыйлаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә, 8.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«8.5. Ачык тәкъдим аша сатуда катнашу өчен, дәгъва итүче түбәндәге күләмдә алдан түләү кертә:

Муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән һәм 100 миллион сум һәм аннан да күбрәк суммада күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 проценты;

Муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән һәм 100 миллион сумнан ким булган башлангыч бәянең 10 проценты.

Мәгълүмат хәбәрендә күрсәтелгән счетка алдан түләү кертүне раслаучы документ әлеге счеттан өземтә булып тора.».

2. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов